ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

22 июнь 2018 ел № 3597

Башкарма комитетның «Торак шартларын яхшыртуга мохтаҗлар буларак исәпкә кую һәм күчеп китәргә мәҗбүр булганнарга торак сатып алу өчен субсидия бирүгә Дәүләт торак сертификаты бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2013 елның 2 октябрендәге 5951 нче карарына үзгәрешләр кертү турында

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ санлы Федераль закон, шәһәр Уставының 42 маддәсе, Шәһәр Советының 2007 елның 21 февралендәге 19/8 нче карары белән расланган Муниципаль хокукый актлар системасы турында нигезнамәнең 5.24 пункты нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның «Торак шартларын яхшыртуга мохтаҗлар буларак исәпкә кую һәм күчеп китәргә мәҗбүр булганнарга торак сатып алу өчен субсидия бирүгә Дәүләт торак сертификаты бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2013 елның 2 октябрендәге 5951 нче карарына (Башкарма комитетның 2016 елның 27 июнендәге 3254 нче карары редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) преамбуланы түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ санлы Федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясенең «Россия Федерациясе гражданнарын һәркем ала алырлык һәм комфортлы торак һәм коммуналь хезмәтләр белән тәэмин итү» дәүләт программасының аерым чараларын тормышка ашыру турында» 2010 елның 17 декабрендәге 1050 нче карары, Татарстан Республикасының «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ санлы Законы, Россия Федерациясе

Хөкүмәтенең «Россия Федерациясе гражданнарын һәркем ала алырлык һәм комфортлы торак һәм коммуналь хезмәтләр белән тәэмин итү» Россия Федерациясе дәүләт программасының «Федераль законнарда билгеләнгән гражданнар категорияләрен торак белән тәэмин итү буенча дәүләт йөкләмәләрен үтәү» төп чарасын тормышка ашыруның кайбер мәсьәләләре турында» 2006 елның 21 мартындагы 153 нче карары, шәһәр Уставының 42 маддәсе, Башкарма комитетның 2016 елның 13 маендагы 2363 нче карары белән расланган Башкарма комитет тарафыннан күрсәтелә торган муниципаль хезмәтләр исемлеге нигезендә»;

2) кушымтаны кушымтада каралганча яңа редакциядә бәян итәргә.

2. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Р.Ә. Абдуллин

Башкарма комитетның
2018 елның 22 июнендәге
3597 нче карарына
кушымта

Торак шартларын яхшыртуга мохтаҗлар буларак исәпкә кую һәм күчеп китәргә мәҗбүр булганнарга торак сатып алу өчен субсидия бирүгә Дәүләт торак сертификаты бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты (алга таба – Регламент) торак шартларын яхшыртуга мохтаҗлар буларак исәпкә кую һәм күчеп китәргә мәҗбүр булганнарга торак сатып алу өчен субсидия бирүгә Дәүләт торак сертификаты бирү буенча муниципаль хезмәт (алга таба – муниципаль хезмәт) күрсәтү стандартын һәм тәртибен билгели.

1.2. Муниципаль хезмәттән файдаланучылар: физик затлар (алга таба – гариза бирүче).

1.3. Муниципаль хезмәт Татарстан Республикасы Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты тарафыннан күрсәтелә (алга таба – Башкарма комитет).

Муниципаль хезмәтне үтәүче – архитектура, шәһәр төзелешен һәм торакны үстерү идарәсенең торакны үстерү бүлеге (алга таба – Бүлек); Башкарма комитетның Комсомол, Үзәк һәм Автозавод районнары Хакимиятләре (алга таба – районнар Хакимияте).

1.3.1. Башкарма комитетның урнашу урыны: Татарстан Республикасы, Яр Чаллы шәһәре, Хәсән Туфан проспекты, 23 йорт.

Бүлек – Хәсән Туфан проспекты, 23 йорт, 222 кабинет.

Районнар Хакимиятенең урнашу урыны: Татарстан Республикасы, Яр Чаллы шәһәре:

Комсомол районы – ГЭС, 8/7 йорт, 5, 7 кабинетлар.

Үзәк районы – Яңа шәһәр, 3/08 йорт, 103 кабинет.

Автозавод районы – Яңа шәһәр, 49/09 йорт, 101 кабинет.

Районнар Хакимиятенең эш графигы:

Дүшәмбе – җомга: 8.00 дән 17.00 сәгатькә кадәр;

Шимбә һәм якшәмбе – ял көннәре.

Төшке аш вакыты 12.00 дән 13.00 сәгатькә кадәр.

Районнар Хакимиятенең белешмә өчен телефоннары:

Идарә – 30-56-53;

Комсомол районы – 70-45-46;

Үзәк районы – 47-55-72;

Автозавод районы – 56-74-16.

Керү шәхесне таныклаучы документлар буенча.

1.3.2. «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә (алга таба – «Интернет» челтәре) Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге рәсми сайтының адресы: http://www.nabchelny.ru.

1.3.3. Муниципаль хезмәт турындагы мәгълүматны түбәндәге ысуллар аша алырга мөмкин:

1) Башкарма комитет бүлмәләрендә гариза бирүчеләр белән эшләү өчен куелган, муниципаль хезмәт турында визуаль һәм текстлы мәгълүмат булган мәгълүматлар стенды аша;

2) Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең «Интернет» челтәрендәге рәсми сайты аша (http://www.nabchelny.ru);

3) Татарстан Республикасының дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталында (http://uslugi.tatar.ru/);

4) Бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) порталында (http://www.gosuslugi.ru/);

5) Башкарма комитетта (районнар Хакимиятендә):

телдән мөрәҗәгать иткәндә – шәхсән яки телефон аша;

язма рәвештә мөрәҗәгать иткәндә (шул исәптән электрон документ рәвешендә) – почта аша кәгазь йөрткечтә, электрон почта аша электрон рәвештә.

1.3.4. Муниципаль хезмәтләр күрсәтү мәсьәләләре буенча мәгълүмат районнар Хакимияте белгечләре тарафыннан рәсми сайтта һәм Башкарма комитетта гариза бирүчеләр белән эшләү өчен куелган мәгълүмат стендларында урнаштырыла.

1.4. Муниципаль хезмәт күрсәтү түбәндәгеләр нигезендә гамәлгә ашырыла:

2004 елның 29 декабрендәге 188-ФЗ санлы Россия Федерациясе Торак кодексы (алга таба – РФ Торак кодексы) (РФ законнар җыентыгы, 03.01.2005, №1 (1 өлеш, ст. 14);

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ санлы Федераль закон (алга таба – 210-ФЗ санлы Федераль закон) (РФ законнар җыентыгы, 02.08.2010);

Татарстан Республикасының «Татарстан Республикасы дәүләт торак фондыннан һәм муниципаль торак фондыннан социаль наем килешүләре буенча гражданнарның аларга торак урыннары бирү хокукларын тормышка ашыру турында» 2007 елның 13 июлендәге 31-ТРЗ санлы Законы (Республика Татарстан, №144, 20.07.2007) (алга таба – 31-ТРЗ санлы ТР Законы);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясе гражданнарын һәркем ала алырлык һәм комфортлы торак һәм коммуналь хезмәтләр белән тәэмин итү» Россия Федерациясе дәүләт программасының «Федераль законнарда билгеләнгән гражданнар категорияләрен торак белән тәэмин итү буенча дәүләт йөкләмәләрен үтәү» төп чарасын тормышка ашыруның кайбер мәсьәләләре турында» 2006 елның 21 мартындагы 153 нче карары (алга таба – Кагыйдәләр) (РФ законнар җыентыгы, 27.03.2006, №13, ст. 1406);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясенең «Россия Федерациясе гражданнарын һәркем ала алырлык һәм комфортлы торак һәм коммуналь хезмәтләр белән тәэмин итү» дәүләт программасының аерым чараларын тормышка ашыру турында» 2010 елның 17 декабрендәге 1050 нче карары (алга таба – 1050 нче карар) (РФ законнар җыентыгы, 31.01.2011, №5, ст. 739);

Татарстан Республикасының «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ санлы Законы (алга таба – 45-ТРЗ санлы ТР Законы) (Республика Татарстан, №155-156, 03.08.2004);

Татарстан Республикасының «Татарстан Республикасында торак төзелешен үстерүгә дәүләт ярдәме турында» 2004 елның 27 декабрендәге 69-ТРЗ санлы Законы (алга таба – 69-ТРЗ санлы ТР Законы) (Республика Татарстан, №157, 07.08.2007);

Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Вәкиллекле органы тарафыннан расланган Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Уставы 2005 елның 8 декабре, №6/5 (алга таба – Устав);

Яр Чаллы шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесенең 2008 елның 31 декабрендәге 1422 нче боерыгы белән расланган Комсомол, Үзәк, Автозавод районнары Хакимияте турында нигезнамә (алга таба – район Хакимияте турында нигезнамә);

Башкарма комитет Җитәкчесенең 2007 елның 16 июлендәге 754 нче боерыгы белән расланган Башкарма комитетның Эчке хезмәт тәртибе кагыйдәләре (алга таба – Эчке тәртип кагыйдәләре).

1.5. Регламентта түбәндәге терминнар һәм билгеләмәләр кулланыла:

дәүләт торак сертификаты (алга таба – сертификат) гражданның торак сатып алу өчен федераль бюджет акчалары хисабына социаль түләү (торак субсидиясе, субсидия) алуга хокукын раслаучы исемле таныклык булып тора;

торак сатып алу өчен социаль түләү – 2015-2020 елларга «Торак» федераль максатчан программасының «Федераль законнарда билгеләнгән гражданнар категорияләрен торак белән тәэмин итү буенча дәүләт йөкләмәләрен үтәү» ярдәмче программасы кысаларында гражданнарны торак белән тәэмин итүдә дәүләт финанс ярдәме күрсәтүнең дәүләт торак сертификаты белән раслана торган формасы.

Әлеге Регламентта муниципаль хезмәт күрсәтү турында гариза дигәндә (алга таба – гариза) муниципаль хезмәт күрсәтү турындагы запрос аңлашыла (2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ санлы Федераль законның 2 маддәсенең 2 пункты). Гариза әлеге Регламентка 1, 2, 3 нче кушымталарда каралган форма буенча тутырыла.

## 2. Муниципаль хезмәт күрсәтү стандарты

| Муниципаль хезмәт күрсәтү стандартына таләпләр исеме | Стандартка таләпләрнең эчтәлеге | Хезмәтне яки таләпне билгеләүче норматив акт |
| --- | --- | --- |
| 2.1. Муниципаль хезмәтнең исеме | Торак шартларын яхшыртуга мохтаҗлар буларак исәпкә кую һәм күчеп китәргә мәҗбүр булганнарга торак сатып алу өчен субсидия бирүгә Дәүләт торак сертификаты бирү | РФ Торак кодексы;<br>Татарстан Республикасының 2007 елның 13 июлендәге 31-ТРЗ санлы Законы;<br>Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2010 елның 17 декабрендәге 1050 нче карары;<br>Кагыйдәләр (Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2006 елның 21 мартындагы 153 нче Карары) |
| 2.2. Турыдан-туры муниципаль хезмәт күрсәтүче органның исеме | Районнар Хакимияте йөзендә Татарстан Республикасы Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты | Шәһәр Уставы |
| 2.3. Муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсенең тасвирламасы | Башкарма комитет карары:<br>1) торак шартларын яхшыртуга мохтаҗлар буларак исәпкә кую турында;<br>2) торак шартларын яхшыртуга мохтаҗлар буларак исәпкә куюны кире кагу турында.<br>Дәүләт торак сертификаты | РФ Торак кодексы;<br>Татарстан Республикасының 2007 елның 13 июлендәге 31-ТРЗ санлы Законы;<br>Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2010 елның 17 декабрендәге 1050 нче карары;<br>Кагыйдәләр |

| | | |
|---|---|---|
| | | (Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2006 елның 21 мартындагы 153 нче Карары) |
| 2.4. Муниципаль хезмәт күрсәтү срогы | Гариза кергән вакыттан башлап 30 эш көне эчендә карар чыгару.<br>Сертификатлар кергән вакыттан башлап ике көннән артмаган срокта сертификат бирү.<br>Чират җитүен көткән вакыт муниципаль хезмәт күрсәтү срогына керми | |
| 2.5. Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен, шулай ук муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булып торган хезмәтләрне күрсәтү өчен, закон яки башка норматив хокукый актлар нигезендә кирәкле, гариза бирүче тапшырырга тиешле документларның тулы исемлеге | <u>Торак шартларын яхшыртуга мохтаҗлар буларак исәпкә кую өчен:</u><br>1) Гариза (1 нче кушымта);<br>2) Гаиләнең күрсәтелгән статуска ия һәр балигъ булган әгъзасына күчеп китәргә мәҗбүр булучының таныклык күчермәсе;<br>3) Гариза бирүче-гражданның һәм аның гаилә әгъзаларының паспорт һәм шәхесне таныклаучы башка документларының күчермәләре;<br>4) Гариза бирүче-гражданның гаилә составы турында документларының күчермәләре (туу турында таныклык, язылышу турында таныклык, уллыкка (кызлыкка) алу турында карар, гаилә әгъзасы дип тану турында суд карары һ.б.);<br>5) Гариза бирүче-граждан һәм аның гаилә әгъзалары тарафыннан биләнә торган торак бүлмәдән файдалану хокукын раслаучы документларның күчермәләре (килешү, ордер, торак бүлмә бирү турында карар һәм башка документлар); | РФ Торак кодексы;<br>Татарстан Республикасының 2007 елның 13 июлендәге 31-ТРЗ санлы Законы |

| | | |
|---|---|---|
| | 6) Йорт кенәгәсеннән өземтә;<br>7) Гаиләнең һәр әгъзасы тарафыннан тапшырыла торган милекчелек хокукындагы торак бүлмәләр булу яки булмау турында дәүләт теркәү органнарыннан белешмә (1999 елның 31 декабренә кадәр);<br>8) Вәкил вәкаләтләрен раслаучы документ (гариза бирүче исеменнән вәкил эш иткән очракта).<br>Барлык документларның да күчермәләре белән бергә аларның төп нөсхәләрен дә тапшыру тәкъдим ителә.<br><u>Торак сатып алу өчен субсидия бирүгә Дәүләт торак сертификаты алу өчен:</u><br>1) Башкарма комитет Җитәкчесе исеменә планлаштырылган елда сертификат бирү турында гариза;<br>2) Төп чарада катнашучылар составына кертү турында гариза (рапорт) (2 нче кушымта);<br>3) Дәүләт торак сертификаты бирү турында гариза (рапорт) (3 нче кушымта);<br>4) Персональ мәгълүматларны эшкәртүгә ризалык (4 нче кушымта);<br>5) Гаиләнең күрсәтелгән статуска ия һәр балигъ булган әгъзасына күчеп китәргә мәҗбүр булучының таныклык күчермәсе;<br>6) Гариза бирүче-гражданның һәм аның гаилә әгъзаларының паспорт һәм шәхесне таныклаучы башка документларының күчермәләре;<br>7) Вәкил вәкаләтләрен раслаучы документ (гариза бирүче исеменнән вәкил эш иткән очракта);<br>8) Өстәмә торак мәйданына хокукны раслаучы | <br><br><br><br><br><br><br><br><br>Кагыйдәләрнең 19 пункты (Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2006 елның 21 мартындагы 153 нче Карары) |

| | | |
|---|---|---|
| | документ күчермәсе (Россия Федерациясе законнары нигезендә шундый хокук бирелгән очракларда);<br>9) даими яшәү өчен торак бүлмә, торак төзү (сатып алу) өчен ссуда яки социаль түләү яисә югалткан торак бүлмә өчен компенсация алу (алмау) турында миграция өлкәсендә контроль органыннан белешмә.<br>Барлык документларның да күчермәләре белән бергә аларның төп нөсхәләрен дә тапшыру тәкъдим ителә | |
| 2.6. Муниципаль хезмәте күрсәтү өчен норматив хокукый актлар нигезендә кирәкле, дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм башка оешмалар карамагындагы һәм гариза бирүче тапшырырга хокуклы документларның тулы исемлеге | Ведомствоара хезмәттәшлек кысаларында түбәндәгеләр алына:<br>1) күчемсез милеккә һәм аның белән килешүләр төзүгә хокукларның Бердәм дәүләт реестрыннан аерым затның булган (булдырган) күчемсез милек объектларына хокуклары турында өземтә (гаиләнең һәр әгъзасы өчен);<br>2) күчемсез милеккә һәм аның белән килешүләр төзүгә хокукларның Бердәм дәүләт реестрыннан хокукларның күчемсез милек объектына күчүе турында өземтә | |
| 2.7. Норматив хокукый актларда каралган очракларда, хезмәт күрсәтү өчен килешенү (муниципаль хезмәтне күрсәтүче орган тарафыннан гамәлгә ашырыла) таләп ителә торган дәүләт хакимияте органнары (җирле үзидарә органнары) һәм аларның структур бүлекчәләренең исемлеге | 1) Башкарма комитетның районнар Хакимияте;<br>2) Башкарма комитетның архитектура, шәһәр төзелешен һәм торакны үстерү идарәсе;<br>3) Башкарма комитетның хокук идарәсе;<br>4) Башкарма комитет Аппараты Җитәкчесе;<br>5) Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсе | |

| | | |
|---|---|---|
| 2.8. Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүне кире кагу өчен нигезләрнең тулы исемлеге | 1) Документлар тиешле булмаган зат тарафыннан тапшырылу;<br>2) Тапшырылган документлар Регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән документлар исемлегенә туры килмәү;<br>3) Гариза текстын уку мөмкин булмау;<br>4) Документларны тиешле булмаган органга тапшыру | |
| 2.9. Муниципаль хезмәт күрсәтүне туктату яки кире кагу өчен нигезләрнең тулы исемлеге | Муниципаль хезмәт күрсәтүне туктату өчен нигез каралмаган.<br>Кире кагу өчен нигез:<br>1) гариза бирүче тапшырган документларда дөрес булмаган мәгълүмат ачыклану;<br>2) Гражданның торакка мохтаҗлар буларак исәптә тору хокукын расламый торган документлар тапшырылу;<br>3) Элек торак шартларын яхшыртуга хокук тормышка ашырылу яки федераль бюджет акчалары хисабына бирелгән социаль түләүдән яки субсидиядән файдаланып торак белән тәэмин ителү;<br>4) Торак шартлары начарлануга китергән гамәлләр булган көннән соң срок (биш ел) узмаган булу;<br>5) Тиешле документ үз инициативасы буенча гариза бирүче тарафыннан тапшырылмаган очракта, муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документ һәм (яки) мәгълүмат булмауны раслаучы ведомствоара запроска дәүләт хакимияте органының, җирле үзидарә органының яисә дәүләт хакимияте органы яки җирле үзидарә органы карамагындагы | РФ Торак кодексы;<br>Татарстан Республикасының 2007 елның 13 июлендәге 31-ТРЗ санлы Законы;<br>Кагыйдәләрнең 22 пункты (Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2006 елның 21 мартындагы 153 нче Карары) |

| | | |
|---|---|---|
| | оешманың җавабы керү;<br>6) Регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән документларны тапшырмау яки тулы булмаган күләмдә тапшыру | |
| 2.10. Хезмәт күрсәтү өчен алына торган дәүләт пошлинасы яки башка түләү алу тәртибе, күләме һәм нигезләре | Муниципаль хезмәт түләүсез нигездә күрсәтелә | |
| 2.11. Хезмәт күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган хезмәтләр күрсәтү өчен түләү алу тәртибе, күләме һәм нигезләре, шундый түләү күләмен исәпләү методикасы турындагы мәгълүматны кертеп | Кирәкле һәм мәҗбүри хезмәтләр күрсәтү таләп ителми | |
| 2.12. Муниципаль хезмәт күрсәтү турында запрос биргәндә һәм муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәләрен алганда чиратта көтүнең максималь срогы | Чират булганда, муниципаль хезмәт алуга гариза бирү – 15 минуттан да артык түгел.<br>Муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәләрен алганда чиратта көтү срогы 15 минуттан артырга тиеш түгел | |
| 2.13. Муниципаль хезмәт күрсәтү турында гариза бирүченең запросын теркәү срогы | Гариза кергән вакыттан башлап бер көн эчендә | |
| 2.14. Муниципаль хезмәт күрсәтелә торган биналарга, гариза бирүчеләрне кабул итү, аларның көтеп тору урыннарына, шул исәптән Россия Федерациясенең инвалидларны | Муниципаль хезмәт күрсәтү янгынга каршы система һәм янгын сүндерү системасы, документлар тутыру өчен кирәкле мебель, мәгълүмат стендлары белән җиһазландырылган бина һәм бүлмәләрдә гамәлгә ашырыла.<br>Инвалидларга муниципаль хезмәт күрсәтү урынына | |

| | | |
|---|---|---|
| социаль яклау турындагы законнары нигезендә күрсәтелгән объектларның инвалидлар өчен уңайлылыгын тәэмин итүгә, андый хезмәтләр күрсәтү тәртибе турындагы визуаль, текстлы һәм мультимедия мәгълүматын урнаштыру һәм рәсмиләштерүгә таләпләр | тоткарлыксыз керү тәэмин ителә (бинага уңайлы керү-чыгу, аның чикләрендә хәрәкәтләнү).<br>Муниципаль хезмәтләр күрсәтү тәртибе турындагы визуаль, текстлы һәм мультимедия мәгълүматы мөрәҗәгать итүчеләр өчен уңайлы урыннарда урнаштырыла, шул исәптән мөмкинлекләре чикле инвалидларны да истә тотып | |
| 2.15. Муниципаль хезмәтнең һәркем алырлык булуы һәм сыйфаты күрсәткечләре | Муниципаль хезмәтнең һәркем алырлык булуы һәм сыйфаты күрсәткечләре булып түбәндәгеләр тора:<br>1) документларны кабул итү һәм карау срокларын үтәү;<br>2) муниципаль хезмәт нәтиҗәсен алуның срогын үтәү;<br>3) муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан Административ регламентны бозу прецедентлары (дәлилле шикаятьләр) булу.<br>Муниципаль хезмәтне дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүче күпфункцияле үзәктә (алга таба – Күпфункцияле үзәк) күрсәткәндә консультация бирүне, документлар кабул итү һәм бирүне Күпфункцияле үзәк белгече гамәлгә ашыра | |
| 2.16. Муниципаль хезмәтне электрон рәвештә күрсәтүнең үзенчәлекләре | Муниципаль хезмәт күрсәтү тәртибе турындагы консультацияне электрон рәвештә Интернет-кабул итүе яки Татарстан Республикасының дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы аша алырга мөмкин. Әгәр законда муниципаль хезмәт күрсәтү турында электрон рәвештә гариза бирү каралган булса, ул | |

| | | |
|---|---|---|
| | очракта гариза Татарстан Республикасының дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы (http://uslugi. tatar.ru/) яки Бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) порталы аша (http:// www.gosuslugi.ru/) бирелә | |

## 3. Административ процедураларның (гамәлләрнең) составы, эзлеклелеге һәм үтәү сроклары, аларны үтәү тәртибенә таләпләр, шул исәптән административ процедураларны (гамәлләрне) электрон рәвештә үтәү үзенчәлекләре

3.1. Муниципаль хезмәт күрсәткәндә гамәлләрнең эзлеклелеген тасвирлау

3.1.1. Муниципаль хезмәт күрсәтү түбәндәге процедураларны үз эченә ала:

1) гариза бирүчегә консультация бирү;

2) гаризаны кабул итү һәм теркәү;

3) ведомствоара запросларны формалаштыру һәм аларны муниципаль хезмәт күрсәтүдә катнашучы органга җибәрү;

4) документларны карап тикшерү өчен комиссиягә җибәрү;

5) материалларны комиссия тарафыннан карап тикшерү;

4) муниципаль хезмәт нәтиҗәсен әзерләү;

5) гариза бирүчегә муниципаль хезмәт нәтиҗәсен бирү.

3.1.2. Муниципаль хезмәт күрсәтү буенча гамәлләр эзлеклелегенең блок-схемасы әлеге Регламентка 5 нче кушымтада күрсәтелгән.

3.2. Гариза бирүчегә консультацияләр бирү

3.2.1. Гариза бирүче, муниципаль хезмәттән файдалану тәртибе турындагы консультацияләрне телефон һәм (яки) электрон почта аша алу өчен, район Хакимиятенә мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

Район Хакимияте белгече гариза бирүчегә консультация бирә, шул исәптән муниципаль хезмәттән файдалануның составы, тапшырыла торган документларның формасы һәм башка мәсьәләләр буенча һәм кирәк булганда, гариза бланкын тутыруда ярдәм күрсәтә.

Әлеге пунктта билгеләнгән процедуралар гариза бирүче мөрәҗәгать иткән көндә гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: тапшырыла торган документлар составы, формасы һәм рөхсәт алуга кагылышлы башка мәсьәләләр буенча консультацияләр.

3.3. Гаризаны кабул итү һәм теркәү

3.3.1. Гариза бирүче шәхсән яки ышанычлы зат аша район Хакимиятенә язмача гариза бирә һәм әлеге Регламентның 2.5 пункты нигезендә документлар тапшыра.

Муниципаль хезмәт күрсәтү турындагы электрон рәвештәге гариза район Хакимиятенә электрон почта яки Интернет-кабул итүе аша җибәрелә. Электрон рәвештә кергән гаризаны теркәү билгеләнгән тәртиптә гамәлгә ашырыла.

3.3.2. Район Хакимиятенең гаризалар кабул итүне алып баручы белгече түбәндәгеләрне гамәлгә ашыра:

гариза бирүченең шәхесен аныклый;

гариза бирүченең вәкаләтләрен тикшерә (ышаныч язуы белән эш иткән очракта);

әлеге Регламентның 2.5 пунктында каралган документларның булуын тикшерә;

тапшырылган документларның билгеләнгән таләпләргә туры килүен тикшерә.

Кимчелекләр булмаган очракта, район Хакимияте белгече түбәндәгеләрне гамәлгә ашыра:

гаризаны кабул итә һәм махсус журналда терки;

гариза бирүчегә, документларны кабул итү датасы, теркәгәндә бирелгән керү номеры, муниципаль хезмәт күрсәтүне үтәү датасы һәм вакыты турында билге куеп, тапшырылган документлар исемлегенең күчермәсен бирә.

Документлар кабул итүне кире кагу өчен әлеге Регламентның 2.8 пунктында каралган нигезләр булган очракта, район Хакимиятенең гаризалар кабул итүне алып баручы белгече гариза бирүчегә гаризаны теркәү өчен каршылыклар булуы турында хәбәр итә һәм документлар кабул итүне кире кагу өчен ачыкланган сәбәпләрне язмача аңлатып, документларын кире кайтара.

Әлеге пунктта билгеләнгән процедуралар 15 минут эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: кабул ителгән һәм теркәлгән гариза һәм гариза бирүчегә кире кайтарылган документлар.

3.4. Ведомствоара запросларны формалаштыру һәм аларны муниципаль хезмәт күрсәтүдә катнашучы органга җибәрү

3.4.1. Район Хакимияте белгече ведомствоара электрон хезмәттәшлек системасы аша электрон рәвештә күчемсез милеккә һәм аның белән килешүләр төзүгә хокукларның Бердәм дәүләт реестрыннан аерым затның булган күчемсез милек объектларына хокуклары турында өземтә (һәр гаилә әгъзасына) бирү хакында запрос җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнгән процедуралар муниципаль хезмәт күрсәтү турында гариза кергән вакыттан башлап бер көн эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: җибәрелгән запрослар.

3.4.2. Мәгълүмат бирүченең белгечләре, ведомствоара электрон хезмәттәшлек системасы аша кергән запрос нигезендә, соралган документларны (мәгълүматны) бирәләр яки муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларның һәм (яки) мәгълүматның булмавы турында хәбәр җибәрәләр (алга таба – кире кагу турында хәбәр итү).

Әлеге пунктта билгеләнгән процедуралар документ һәм мәгълүмат бирүче орган яки оешмага ведомствоара запрос кергән көннән башлап биш көн эчендә гамәлгә ашырыла, әгәр Россия Федерациясе Хөкүмәтенең федераль законнарында, хокукый актларында һәм Татарстан Республикасының федераль законнар нигезендә кабул ителгән норматив хокукый актларында ведомствоара запроска җавап әзерләү һәм җибәрүнең башка сроклары билгеләнмәгән булса.

Процедураларның нәтиҗәсе: район Хакимиятенә җибәрелгән документлар (мәгълүматлар) яисә кире кагу турында хәбәр.

3.5. Муниципаль хезмәт нәтиҗәсен әзерләү

3.5.1. Район Хакимияте белгече, норматив хокукый базаны исәпкә алып, гаризаны һәм документларны өйрәнә, карап тикшерә.

Муниципаль хезмәт күрсәтүне кире кагу өчен әлеге Регламентның 2.9 пунктында күрсәтелгән нигезләр булмаган очракта, район Хакимияте белгече торак шартларын яхшыртуга мохтаҗлар буларак исәпкә кую турында карар проектын әзерләүне гамәлгә ашыра һәм килешенү өчен район Хакимияте Башлыгына җибәрә.

Муниципаль хезмәт күрсәтүне кире кагу өчен әлеге Регламентның 2.9 пунктында күрсәтелгән нигезләр булган очракта, район Хакимияте белгече аның гаризасын һәм документларын район Хакимиятенең иҗтимагый торак комиссиясе (алга таба – Комиссия) утырышында карап тикшерү турында гражданга хәбәр җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнгән процедуралар запросларга җаваплар кергән вакыттан башлап өч көн эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе:

1) килешенү өчен район Хакимияте Башлыгына җибәрелгән торак шартларын яхшыртуга мохтаҗлар буларак исәпкә кую турында Башкарма комитет карары проекты;

2) гаризасын һәм документларын комиссия утырышында карап тикшерү турында гражданга җибәрелгән хәбәр.

3.5.2. Билгеләнгән көнне Комиссия граждан катнашында документларны карап тикшерә, карар кабул итә һәм аны, торак шартларын яхшыртуга мохтаҗлар буларак исәпкә куюны кире кагу турында Башкарма комитет карары проектын әзерләү өчен, район Хакимияте белгеченә җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнгән процедура бер көн эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: торак шартларын яхшыртуга мохтаҗлар буларак исәпкә куюны кире кагу турында Башкарма комитет карары проектын әзерләү өчен, район Хакимияте белгеченә җибәрелгән Комиссия карары.

3.5.3. Район Хакимияте Башлыгы документларны карап тикшерә һәм торак шартларын яхшыртуга мохтаҗлар буларак исәпкә кую турында яки исәпкә куюны кире кагу турында карар проектын килешенү турында һәм аны килешенү өчен Башкарма комитетның архитектура, шәһәр төзелешен һәм торакны үстерү идарәсе башлыгы урынбасарына (алга таба – Идарә башлыгы урынбасары) җибәрү турында карар кабул итә.

Әлеге пунктта билгеләнгән процедуралар запросларга җаваплар кергән вакыттан башлап өч көн эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: Идарә башлыгы урынбасарына җибәрелгән карар проекты.

3.5.4. Идарә башлыгы урынбасары документларны карап тикшерә һәм торак шартларын яхшыртуга мохтаҗлар буларак исәпкә кую турында яки исәпкә куюны кире кагу турында карар проектын килешенү турында һәм аны имзалау өчен Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары, архитектура,

шәһәр төзелешен һәм торакны үстерү идарәсе башлыгына (алга таба – Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары) җибәрү турында карар кабул итә.

Әлеге пунктта билгеләнгән процедуралар алдагы процедура тәмамланган вакыттан башлап бер көн эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасарына җибәрелгән карар проекты.

3.5.5. Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары документларны карап тикшерә һәм торак шартларын яхшыртуга мохтаҗлар буларак исәпкә кую турында яки исәпкә куюны кире кагу турында карар проектын килешенү турында һәм аларны килешенү өчен Башкарма комитетның хокук идарәсенә (алга таба – Хокук идарәсе) җибәрү турында карар кабул итә.

Әлеге пунктта билгеләнгән процедуралар алдагы процедура тәмамланган вакыттан башлап бер көн эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: килешенү өчен Хокук идарәсенә җибәрелгән торак шартларын яхшыртуга мохтаҗлар буларак исәпкә кую турында яки исәпкә куюны кире кагу турында Башкарма комитет карары проекты.

3.5.6. Хокук идарәсе торак шартларын яхшыртуга мохтаҗлар буларак исәпкә кую турында яки исәпкә куюны кире кагу турында карар проектын карап тикшерә һәм Башкарма комитет Аппараты Җитәкчесенә җибәрә.

Тапшырылган документлар норматив хокукый актларга туры килмәгән очракта, Хокук идарәсе торак шартларын яхшыртуга мохтаҗлар буларак исәпкә кую турында яки исәпкә куюны кире кагу турында карар проектына карата кимчелекләр әзерли һәм әлеге кимчелекне төзәтү өчен район Хакимияте белгеченә җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнгән процедуралар торак шартларын яхшыртуга мохтаҗлар буларак исәпкә кую турында яки исәпкә куюны кире кагу турында карар проекты килешенү өчен Хокук идарәсенә җибәрелгән вакыттан башлап өч көн эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: килешенгән һәм килешенү өчен Башкарма комитет Аппараты Җитәкчесенә җибәрелгән торак шартларын яхшыртуга мохтаҗлар буларак исәпкә кую турында яки исәпкә куюны кире кагу турында карар проекты, яисә район Хакимияте белгеченә җибәрелгән торак шартларын яхшыртуга мохтаҗлар буларак исәпкә кую турында яки исәпкә куюны кире кагу турында карар проектына карата кимчелекләр.

3.5.7. Хокук идарәсе тарафыннан торак шартларын яхшыртуга мохтаҗлар буларак исәпкә кую турында яки исәпкә куюны кире кагу турында карар проектына карата кимчелекләр җибәрелгән очракта, районнар Хакимияте белгече торак шартларын яхшыртуга мохтаҗлар буларак исәпкә кую турында яки исәпкә куюны кире кагу турында карар проекты буенча Хокук идарәсе кимчелекләрен төзәтә һәм аны алга таба килешенү өчен Хокук идарәсенә җибәрә.

Процедураның нәтиҗәсе: төзәтелгән һәм Хокук идарәсенә җибәрелгән торак шартларын яхшыртуга мохтаҗлар буларак исәпкә кую турында яки

исәпкә куюны кире кагу турында Башкарма комитет карары проекты.

3.5.8. Башкарма комитет Аппараты Җитәкчесе торак шартларын яхшыртуга мохтаҗлар буларак исәпкә кую турында яки исәпкә куюны кире кагу турында Башкарма комитет карары проектын карап тикшерә, аны килешенә һәм район Хакимияте белгеченә җибәрә.

Процедураның нәтиҗәсе: килешенгән һәм район Хакимияте белгеченә җибәрелгән торак шартларын яхшыртуга мохтаҗлар буларак исәпкә кую турында яки исәпкә куюны кире кагу турында Башкарма комитет карары проекты.

3.5.9. Район Хакимияте белгече килешенгән торак шартларын яхшыртуга мохтаҗлар буларак исәпкә кую турында яки исәпкә куюны кире кагу турында Башкарма комитет карары проектын Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә (алга таба – Эш кәгазьләрен алып бару идарәсе) җибәрә.

3.5.7-3.5.8 пунктларда билгеләнгән процедуралар алдагы процедура тәмамланган вакыттан башлап бер көн эчендә.

Процедураның нәтиҗәсе: килешенгән һәм Эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә җибәрелгән торак шартларын яхшыртуга мохтаҗлар буларак исәпкә кую турында яки исәпкә куюны кире кагу турында Башкарма комитет карары проекты.

3.5.10. Эш кәгазьләрен алып бару идарәсе:

1) торак шартларын яхшыртуга мохтаҗлар буларак исәпкә кую турында яки исәпкә куюны кире кагу турында Башкарма комитет карары проектын ахыргы вариантта карый;

2) вазыйфаи затларның тиешле визалары булуын (булмавын), карар проектын тарату битен тикшерә;

3) торак шартларын яхшыртуга мохтаҗлар буларак исәпкә кую турында яки исәпкә куюны кире кагу турында Башкарма комитет карары проектын Башкарма комитет бланкында бастырып чыгара;

4) торак шартларын яхшыртуга мохтаҗлар буларак исәпкә кую турында яки исәпкә куюны кире кагу турында Башкарма комитет карары проектын имзалау өчен Башкарма комитет Җитәкчесенә җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнгән процедура өч көн эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: имзалау өчен Башкарма комитет Җитәкчесенә җибәрелгән торак шартларын яхшыртуга мохтаҗлар буларак исәпкә кую турында яки исәпкә куюны кире кагу турында Башкарма комитет карары проекты.

3.5.11. Башкарма комитет Җитәкчесе торак шартларын яхшыртуга мохтаҗлар буларак исәпкә кую турында яки исәпкә куюны кире кагу турында Башкарма комитет карары проектын имзалый һәм аны Эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнгән процедура бер көн эчендә гамәлгә ашырыла.

процедураларның нәтиҗәсе: имзаланган һәм Эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә җибәрелгән торак шартларын яхшыртуга мохтаҗлар буларак

исәпкә кую турында яки исәпкә куюны кире кагу турында Башкарма комитет карары проекты.

3.5.12. Эш кәгазьләрен алып бару идарәсе түбәндәгеләрне гамәлгә ашыра:

1) имзаланган торак шартларын яхшыртуга мохтаҗлар буларак исәпкә кую турында яки исәпкә куюны кире кагу турында Башкарма комитет карары проектын карарларны теркәү журналында терки;

2) торак шартларын яхшыртуга мохтаҗлар буларак исәпкә кую турында яки исәпкә куюны кире кагу турында Башкарма комитет карарының күчермәләрен тарату реестры нигезендә җибәрә;

Әлеге пунктта билгеләнгән процедура бер көн эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: теркәлгән һәм район Хакимияте белгеченә җибәрелгән торак шартларын яхшыртуга мохтаҗлар буларак исәпкә кую турында яки исәпкә куюны кире кагу турында Башкарма комитет карары.

3.5.13. Район Хакимияте белгече торак шартларын яхшыртуга мохтаҗлар буларак исәпкә кую турында яки исәпкә куюны кире кагу турында Башкарма комитет карары күчермәсенең бер нөсхәсен гариза бирүченең үзенә бирә яки гаризада күрсәтелгән адрес буенча җибәрә, икенче нөсхәсен Хакимияттә исәп делосында саклау өчен калдыра.

Әлеге пунктта билгеләнгән процедура өч көн эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: гариза бирүчегә бирелгән яки гаризада күрсәтелгән адрес буенча почта аша җибәрелгән торак шартларын яхшыртуга мохтаҗлар буларак исәпкә кую турында яки исәпкә куюны кире кагу турында Башкарма комитет карарының күчермәсе.

3.5.14. Исәпкә куелган һәм планлаштырылган елда субсидия (дәүләт торак сертификаты) алырга теләк белдергән гариза бирүче шәхсән яки ышанычлы зат аша Регламентның 2.5 пункты нигезендә район Хакимиятенә гариза һәм документлар тапшыра.

Әлеге пунктта билгеләнгән процедура алдагы процедура тәмамланган вакыттан башлап бер көн эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: гаризаны һәм документларны кабул итү.

3.5.15. Район Хакимияте белгече субсидия (дәүләт торак сертификаты) алырга теләк белдергән гариза бирүче гражданнарның исемлеген һәм исемлекне Башкарма комитет Җитәкчесенә җибәрү турында хат формалаштыра.

Әлеге пунктта билгеләнгән процедура алдагы процедура тәмамланган вакыттан башлап бер көн эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: имзалау өчен, субсидия алучыларның формалаштырылган исемлеген җибәрү турында район Хакимияте Башлыгына җибәрелгән хат.

3.5.16. Район Хакимияте Башлыгы исемлекне һәм Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасарына исемлек җибәрү турындагы хатны имзалый.

Әлеге пунктта билгеләнгән процедура кергән вакыттан башлап бер көн эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: килешенү өчен, формалаштырылган исемлек җибәрү турында Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасарына җибәрелгән хат.

3.5.17. Бүлек белгече түбәндәгеләрне әзерли:

планлаштырылган елда субсидия алырга теләк белдергән гражданнарның гомуми исемлеген (алга таба – гомуми исемлек) һәм гомуми исемлекне Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгына (алга таба – Министрлык) җибәрү турында хат;

Әлеге пунктта билгеләнгән процедура алдагы процедура тәмамланган вакыттан башлап ике көн эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: килешенү өчен, формалаштырылган гомуми исемлек җибәрү турында Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасарына җибәрелгән хат.

3.5.18. Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары гомуми исемлекне һәм гомуми исемлекне Министрлыкка җибәрү турындагы хатны килешенә һәм имзалау өчен Башкарма комитет Җитәкчесенә җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнгән процедура алдагы процедура тәмамланган вакыттан башлап бер көн эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: Башкарма комитет Җитәкчесенә җибәрелгән хат һәм гомуми исемлек.

3.5.19. Башкарма комитет Җитәкчесе исемлекне Министрлыкка җибәрү турында гомуми исемлекне раслый һәм Бүлек белгеченә тапшыра.

Әлеге пунктта билгеләнгән процедура алдагы процедура тәмамланган вакыттан башлап бер көн эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: Бүлек белгеченә җибәрелгән расланган исемлек һәм хат.

3.5.20. Бүлек белгече имзаланган документны терки, кабул ителгән карар турында район Хакимияте белгеченә хәбәр итә һәм исемлекне хат белән бергә Министрлыкка җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнгән процедура алдагы процедура тәмамланган вакыттан башлап ике көн эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: Министрлыкка җибәрелгән исемлек яки муниципаль хезмәт күрсәтүне кире кагу турында гариза бирүчегә җибәрелгән комиссия карары.

3.6. Муниципаль хезмәт нәтиҗәсен бирү

3.6.1. Министрлык сертификат бланкларын алган датадан башлап 2 ай срокта аларны гражданнар – ярдәмче программада катнашучылар исеменә рәсмиләштерә һәм күрсәтелгән гражданнарга тапшыру өчен сертификатларны шәһәр Башкарма комитетына тапшыра.

Әлеге пунктта билгеләнгән процедура Министрлык регламенты нигезендә гамәлгә ашырыла.

Процедура нәтиҗәсе: Башкарма комитетка җибәрелгән сертификат

банклары.

3.6.2. Бүлек белгече сертификат керү турында район Хакимияте белгеченә хәбәр итә.

Процедураларның нәтиҗәсе: сертификат керү турында район Хакимияте белгеченә хәбәр.

3.6.3. Район Хакимияте белгече сертификат керү турында гариза бирүчегә хәбәр итә.

3.6.2 һәм 3.6.3 пунктларда билгеләнгән процедуралар сертификат кергән вакыттан башлап ике көн эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедура нәтиҗәсе: гариза бирүчегә сертификат керү турында хәбәр.

3.6.4. Гариза бирүче, Бүлеккә килеп, сертификатны имза куеп ала.

Әлеге пунктта билгеләнгән процедура гариза бирүче килгән көнне 15 минут эчендә гамәлгә ашырыла. Аны бирү чират тәртибендә башкарыла.

Процедураның нәтиҗәсе: гариза бирүчегә бирелгән сертификат.

3.7. Ел саен 1 гыйнвардан 1 мартка кадәр районнар Хакимияте торакка мохтаҗлар буларак исәптә торучы гражданнарны кабат терки.

Гражданнарны кабат теркәүне үткәрү өчен, гражданнар үз инициативалары буенча тиешле документларны тапшырмаган очракта, районнар Хакимиятенә 1 апрельгә кадәр запрос буенча әлеге Регламентның 2.6 пунктында каралган документларны алырга кирәк.

